ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Сеҗе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**24 сентябрь 2018** **№32**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда Сеҗе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | - Югары Масра авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау өчен материаллар сатып алу (3 чират);<br>- Гөберчәк авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау һәм материаллар сатып алу;<br>- Курса-Почмак,Гөберчәк авылларында чик буе аншлаглары әзерләү һәм урнаштыру;<br>- Ташкичү авылында Кесмә елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын ремонтлау һәм материаллар сатып алу (2 этап);<br>- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәрү җайланмалары сатып алу һәм урнаштыру; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - Сикертән, Курса-Почмак, Иске Муй авылларында кече архитектура формалары сатып алу һәм балалар мәйданчыкларын төзекләндерү;<br>- Гөберчәк авылында чишмәне төзекләндерү, материаллар сатып алу |
| 2 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | - юл-урам челтәрендәге вак таштан юл полотносына нигез салу һәм каплау.:<br>- Сеҗе авылы, Школьная ур., 11 йорт 12 йорт, 1до, 2 йорт, Вахитов ур., 9 йорт, 16 йорт;<br>- Ташкичү авылы, Такташ ур., 9дан 15кә кадәр<br>- Мөрәле авылы, Центральная урамы, 67дән 72гәчә (2 этап), Үзәк урамы, 33тән 34кә кадәр, Үзәк урамы, 6дан 9га кадәр;Күпер урамы, 13тән 14кә кадәр.<br>- Курса-Почмак авылы, Үзәк урамы, 14тән 17гә кадәр, Овражная урамы киселеше 150м;<br>- Иске Масра авылы, Киров ур., 1дән 1а кадәр, 22додан 23кә кадәр, 1 Май ур., 7дән 9га кадәр<br>- Гөберчәк авылы, М. Мәһдиев ур., 97дән., 100 йорт, 80дән 87 йортка кадәр(2 этап);<br>- Казаклар авылы, Ю. Гагарин ур., 19 йорттан 20кә кадәр;<br>- разъезд Курса авылы, Мәктәп ур., 19 йорт, тимер юл ур., 19 йорт, 23 йорт.<br>- Починок-Поник поселогында Кесмә елгасы аша күпер төзү һәм материаллар сатып алу;<br>- Яңа Чүриле авылында мәктәп һәм Сергин урамнары арасында тимер-бетон боҗралар урнаштырылган дамба урнаштыру (2 этап); |
| 3 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - Мөрәле, Курса-Почмак, Сикертән авыллары өчен янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру (һәр торак пунктка берәр). |
| 4 | Күмү урыннарын карап тоту | - Мөрәле, Яңа Чүриле, Курса разъезды, Югары Масра, Иске Муй,Казаклар авыллары зиратлары өчен мәгълүмат стендлары әзерләү;<br>- Сеҗе авылы зираты территориясендә материаллар сатып алу һәм инвентарь саклау өчен бина урнаштыру; |

Әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Курса-Почмак авылы, Мәктәп урамы,1,Сикертән авылы,Үзәк урамы,14,Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 25..

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Гибадуллина Г.М.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ